КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 12 ноябрь г.Казань № 1019

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 ноябрь, 622 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 декабрь, 622 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 10 декабрь, 706 нчы; 2007 ел, 29 декабрь, 800 нче; 2009 ел, 23 гыйнвар, 35 нче; 2009 ел, 11 декабрь, 849 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 31 гыйнвар, 56 нчы; 2011 ел, 5 март, 177 нче; 2011 ел, 18 ноябрь, 947 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 5 октябрь, 833 нче; 2013 ел, 19 ноябрь, 893 нче; 2014 ел, 21 апрель, 262 нче; 2014 ел, 9 сентябрь, 656 нчы; 2014 ел, 24 декабрь, 1018 нче; 2015 ел, 4 июнь, 409 нчы; 2015 ел, 7 август, 575 нче; 2016 ел, 3 июнь, 370 нче; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 26 сентябрь, 719 нчы; 2018 ел, 27 сентябрь, 869 нчы; 2018 ел, 10 декабрь, 1100 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1295 нче; 2020 ел, 17 апрель, 299 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктта:

беренче абзацта «3629,474» саннарын «3738,394» саннарына алыштырырга;

икенче абзацта «1173,763» саннарын «1208,997» саннарына алыштырырга;

өченче абзацта «2455,711» саннарын «2529,397» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турындагы нигезләмәдә:

3.3 нче пунктның егерме беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге гамәлгә ашырыла торган, төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы $3^8$ һәм $3^9$ өлешләре нигезендә кертелгән үзгәрешләр исәпкә алынган проект документларын кертеп) таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектын файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән тәэмин итү таләпләренә яраклылыгы турында билгеләнгән тәртиптә бирелмәгән бәяләмәсез (алга таба – яраклылык турында бәяләмә) файдалануга тапшырылган объектлар турындагы мәгълүматны Дәүләт статистикасы органнарына һәм Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына җибәрә;»;

3.4 нче пунктта:

«а» пунктчасында «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгәннәрдән башка» сүзләрен «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы $3^3$ өлешендә һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 3 өлешендә каралган очраклардан тыш» сүзләренә алыштырырга;

«б» пунктчасында «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгәннәрдән башка» сүзләрен «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы $3^3$ өлешендә һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 3 өлешендә каралган очраклардан тыш» сүзләренә алыштырырга;

4.1 нче пунктта:

4.1.1 нче пунктчаның икенче абзацында «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгәннәрдән башка» сүзләрен «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы $3^3$ өлешендә һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 3 өлешендә каралган очраклардан тыш» сүзләренә алыштырырга;

4.1.6 нчы пунктчаның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.6. Төзелеше тәмамланган капиталь төзелеш объектын тикшерүне гамәлгә ашырырга, Инспекциянең махсус бланкында башкарылган яраклылык турында бәяләмә бирү турында карар яки мондый бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар кабул итәргә.».

2. Бу карарның 1 нче пунктындагы өченче - бишенче абзацлары гамәле 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин